**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫЗЫЛТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

12 июль, 2019 ел №145

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының "Кызылтау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 сентябрендәге 109 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.6 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"халык арасында яңа төзелгән җирлек булдыру турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артык кеше булмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;»;

б) 3.5 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артык кеше катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта сайлау хокукына ия булган, составына әлеге торак пункт керә торган муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан артмаган вакытка этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Кворум булмаган очракта гражданнар җыеннарының яңа датасын билгеләү муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан башкарыла. Бу очракта гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү билгеләнгән көннән соң ун көннән дә иртәрәк үткәрелергә тиеш түгел.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кызылтау авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Кызылтау авылы**
**җирлеге башлыгы** **Гаффаров Ш.Р.**